СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.06.2021 г.Зеленодольск № 72

2017 елның 20 сентябрендәге 225 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

2009 елның 09 февралендәге «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 8-ФЗ номерлы Федераль закон, 2015 елның 16 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. 2017 елның 20 сентябрендәге 225 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән расланган, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. IV. Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында статистик мәгълүмат бүлегеннән 26 пунктны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль**
**районы Башлыгы, Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**